| ГЛАВА<br>Кичкетанского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Кичкетаң авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.09.2026 Кичкетаң авылы № 2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләренә туры китерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләре турында» 2026 елның 09 сентябрендәге 15-1 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче аерым муниципаль берәмлекләр чикләре турында» карары белән «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлеге Советы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән Татарстан Республикасы чикләренә туры китерү мәсьәләсе буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 2026 елның 25 сентябренә 8.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Кичкетаң авылы, Т.Гыйззәт ур., 4 йорт адресы буенча халык алдында тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларда тикшерелә торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2026 елның 22 сентябренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Кичкетаң авылы, Т.Гыйззәт ур., 4 й.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, веб-адрес буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында Әгерҗе муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru , шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге

җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы, Кичкетаң ур., Т.Гыйззәт ур., 4.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык И.Н. Җиһангәрәев